ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

ПРИКАЗ

21.09.2016 г. Казань № 073-ОД

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитетының
администртив хокук бозулар турында
беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи
затлары исемлеген раслау хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсен үзгәртеп кору мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 31 маендагы 91-ПУ номерлы Указы, «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 09.08.2016 № 541 карары басылып чыгуга бәйле рәвештә һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 4 өлеше нигезендә б о е р ы к  б и р ә м:

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.20 статьясында, 13.25 статьясының 2 өлешендә, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6 һәм 19.7 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларының кушымта итеп бирелүче исемлеген расларга.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең 29.07.2014 № 058 боерыгының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис

И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитетының
21.09.2016 № 073-ОД
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының**
**Архив эше буенча дәүләт комитетының администртив хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар**
**исемлеге**

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе (алга таба – ТР Архив дәүләт комитеты);

ТР Архив дәүләт комитеты рәисе урынбасары;

ТР Архив дәүләт комитетының дәүләт контроле секторы мөдире.